Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге Советы
Карары

2019 елның 24 нче сентябре № 64/3

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлеге Советының 2018 елның 30 октябрендә кабул ителгән 50/3 номерлы “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенына әзерләнү тәртибе турында”гы Нигезләмәне раслау хакында”гы карарына үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында”гы 2019 елның 1 маендагы 87-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 13 пунктының “б” пунктчасы нигезендә, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары һәм “Чуаш Ялтаны авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясына нигезләнеп, Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. 2018 елның 30 октябрендә кабул ителгән 50/3 номерлы “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенына әзерләнү тәртибе турында”гы Нигезләмәне раслау хакында”гы карарына үзгәрешләр кертергә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне әлеге карарның кушымтасына яраклы рәвештә яңа редакциядә бәян итәргә.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

Чистай муниципаль районы
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге башлыгы С.М.Егоров

Чистай муниципаль районы
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге Советының
2019 елның 24 нче сентябрендәге
64\3 нче номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны үткәрү тәртибе турында Нигезләмә**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны уздыру тәртибе турындагы әлеге Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә), “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясына таянып, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына нигезләнеп һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының “Чуаш Ялтаны авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы (алга таба - муниципаль берәмлек) нигезендә эшләнде.

**1.Гомуми нигезләмәләр.**

1.1. Халык җыены гомуми, тигез һәм туры ихтыяр белдерү нигезендә үткәрелә.
1.2. Гражданнар җыенында әлеге торак пунктта яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган кешеләр катнаша ала.
1.3. Гражданнар җыенында катнашу ирекле һәм ихтыярый.
1.4. Гражданнар җыенда шәхсән үзе катнаша һәм аларның һәркайсы бер тавышка ия.
1.5. Халык җыены халык тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатыннан үткәрелә.
1.6. Әгәр, әлеге торак пунктта сайлау хокукына ия кешеләрнең яртысыннан артыгының бер үк вакытта сайлау мөмкинлеге булмаса, Устав нигезендә гражданнар җыены этаплап уздырыла.

**Гражданнар җыенының вәкаләтләре.**

1.7. Гражданнар җыены түбәндәге мәсьәләләр буенча үткәрелә ала:
күрсәтелгән торак пункт аның составына кергән җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча, күрсәтелгән торак пункт территориясе башка җирлек территориясенә күчергә мөмкин булган очракта;
җирлек составына керүче торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;
авыл торак пунктында авыл җирлеге старостасы кандидатурасын тәкъдим итү, шулай ук авыл җирлеге старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча фикер алышу буенча;
авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда конкурс комиссиясе составына кандидатуралар тәкъдим итү максатларында үткәрелергә мөмкин

**Гражданнар җыенын матди һәм оештыру ягыннан тәэмин итү.**

1.8. Җыен муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.
1.9. Җыенга әзерлек һәм аны уздыру белән бәйле чыгымнар муниципаль берәмлек бюджеты хисабына башкарыла.

## 2. Гражданнар җыенының чакырылыш тәртибе

Халык җыены үткәрү инициативасы

2.1. Торак пунктында гражданнар җыенын үткәрү инициативасы түбәндәгеләргә карый:

- муниципаль берәмлек башлыгы;
- кимендә ун кешедән торган сайлау хокукына ия, гражданнар җыенында катнашырга хокукы булган (ягъни Россия Федерациясенең торак пункт территориясендә даими яки күбесенчә яшәүче, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән, 18 яшькә җиткән эшкә сәләтле гражданнар) кешеләр төркеме, шулай ук торак пункт территориясендә даими яки күбесенчә яшәүче һәм җирле үзидарәне тормышка ашырганда Россия Федерациясе һәм федераль законнарның халыкара килешүләре нигезендә хокукларга ия булучы чит ил гражданнары.

2.2. Торак пункт кешеләренең инициативасы имзалар кәгазе (1 нче кушымта) яки инициатив төркем җыелышы беркетмәсе рәвешендә теркәлә, анда түбәндәге мәсьәләләр күрсәтелеп, гражданнар җыены үткәрү инициативасын күрсәтү турында карар кабул ителә:

гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләр;

гражданнар җыенын үткәрү сроклары;

гражданнар җыенын чакыру турындагы инициативаны хуплаучы һәр гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, паспорты яки аны алмаштыручы документының сериясе һәм номеры, яшәү урынындагы адресы, имзасы яки имза куелган дата.

2.3. Җыен үткәрү инициативасын яклап җыелырга тиешле имзалар саны сайлау хокукына ия булган, торак пункт территориясендә даими, яки күбесенчә яшәүче, яшәү урынында теркәлгән гражданнар санының 5 процентын тәшкил итәргә, ләкин 10 имзадан да ким булырга тиеш түгел.

2.4. Имза кәгазьләре имзалар җыючы кешеләр тарафыннан тикшерелә, тикшерү датасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, паспорт, яки аны алмаштыручы документ сериясе һәм номеры, яшәү урынындагы адресы күрсәтелә һәм муниципаль берәмлек башлыгына җибәрелә

### Гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул итү тәртибе

2.5. Инициатив төркем тарафыннан чакырыла торган гражданнар җыены муниципаль берәмлек Советы карары белән (2 нче кушымта), ә муниципаль берәмлек башлыгы инициативасы буенча – муниципаль берәмлек башлыгы карары белән (3 нче кушымта) кирәкле документлар килгән көннән соң 30 көн эчендә билгеләнә.

2.6. Муниципаль берәмлек башлыгы, яки муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы гражданнар җыенын, максатка ярашлы түгел, дип, үткәрүдән баш тартырга тиеш түгел.

2.7. Гражданнар җыенына (гражданнар җыенының этабына) кертелгән мәсьәлә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килергә тиеш түгел. Гражданнар җыены соравы кыска, ягъни аңа бертөрле генә җавап бирергә мөмкин булырлык итеп төзелергә тиеш.

2.8. Гражданнар җыенын билгеләү турындагы карарны рәсми рәвештә бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибе, аны күчерү муниципаль берәмлек Уставы тарафыннан билгеләнә һәм муниципаль берәмлек уставында каралган тәртиптә муниципаль хокук актларын бастырып чыгара (халыкка җиткерә).

Гражданнар җыенын үткәрү турындагы муниципаль берәмлек башлыгы, яки муниципаль берәмлек Советы карарларында гражданнар җыенына кертелә торган сорау, гражданнар җыенын үткәрү вакыты һәм урыны турында мәгълүмат; җыенны оештыручы – муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәләре турында мәгълүматлар күрсәтелә.

2.9.Гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү өчен җаваплы муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсе муниципаль берәмлек башлыгы карары, яки муниципаль берәмлек Советы карары нигезендә, сайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүчеләр исемлеген төзи; гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерли; муниципаль берәмлек халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итә (4 нче кушымта).

Муниципаль берәмлек башкарма комитеты Гражданнар җыенын үткәрү өчен биналар бирергә тиеш.

2.9.1. Этаплап уздырылучы гражданнар җыены турында торак пунктта яшәүчеләргә алдан хәбәр ителергә тиеш, шулай ук исемлекне бүлү һәм халык җыенын үткәрү датасын билгеләү, территориаль, вакытлы билгеләр, башка мәгълүмат күрсәтелергә мөмкин.

2.9.2. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү тәртибе гражданнар җыенын билгеләү турында муниципаль актта күрсәтелә (5,6 нчы кушымталар).

2.9.3. Торак пунктта яшәүчеләр халык җыены (гражданнар җыены этаплары) вакыты һәм урыны турында алдан ук хәбәр ителә. Гражданнар җыенын (гражданнар җыены этапларын) билгеләү турында карар, гражданнар җыенын (гражданнар җыены этапларын) үткәрү вакыты һәм урыны гражданнар җыены (гражданнар җыены этапларын) үткәрелгән көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча басылып чыгарга тиеш. Гражданнар Җыенының этапларын үткәрү вакыты һәм урыны бер карарда яисә халык җыенын билгеләү турында карарда күрсәтелә.

2.9.4. Халык җыенын этаплап уздырган очракта, җыен этаплап уздырыла, гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмый. Халык җыены этапларын күчергәндә, җыенны уздыру билгеләнгән датага кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

2.9.5. Җыенның һәр катнашучысы гражданнар җыенын үткәрү көненә кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсендә әлеге Нигезләмәнеж 2.9. пунктында күрсәтелгәнчщ, гражданнар җыены карарына кертелә торган материаллар белән танышырга, шулай ук аларның күчермәсен алырга хокуклы.

2.10. Гражданнар җыены турындагы Нигезләмә нигезендә гражданнар җыенын үткәрү датасы соңрак  срокка күчерелергә мөмкин. Гражданнар җыенын күчерү турындагы карар җыенны үткәрү билгеләнгән датага кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

## 3. Гражданнар җыенын үткәрү тәртибе

3.1. Җыенга килгән гражданнар җыенда катнашучы кешеләрне теркәү өчен муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан билгеләнгән, җыенда катнашучы, торак пункт кешеләре исемлегенә кертелгән һәм сайлау хокукына ия зат тарафыннан теркәлә. Исемлектә гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урынынагы адресы, паспортының сериясе һәм номеры күрсәтелә.

3.2. Җыенда катнашырга шулай ук  хәлиткеч тавыш бирү хокукы булмаган, ләкин җыенда катнашырга теләк белдергән башка гражданнарга, предприятие, учреждение, оешма җитәкчеләренә, әгәр җыенда тикшерелә торган мәсьәләләрне хәл итү алар эшчәнлеге белән бәйләнгән булса, башка массакүләм мәгълүмат чаралары  вәкилләренә дә рөхсәт ителә.

3.3. Сайлау хокукына ия булучы торак пункт кешеләре исемлегендә төгәлсезлекләр ачыкланган очракта торак пункт кешесе теркәлә, һәм  әлеге муниципаль берәмлек башлыгы аңа җыенда катнашырга рөхсәт бирә.

3.4. Гражданин шәхесен раслаучы (Россия Федерациясе гражданины паспорты, хәрби билеты, чит ил гражданинының паспорты, Россия Федерациясендә яшәүгә рөхсәт, Россия Федерациясендә  вакытлыча яшәүгә рөхсәт) документ язмаларның төгәлсезлеген (яки аларның булмавын) раслау булып хезмәт итә.

3.5. Гражданнар җыены анда сайлау хокукына ия булган торак пункт кешеләренең яртысыннан артыгы катнашканда тулы хокуклы була. Кворум булмаганда гражданнар җыенын үткәрүнең яңа датасын муниципаль  берәмлек башлыгы билгели. Бу очракта гражданнар җыены гражданнар җыены үткәрү билгеләнгән көннән соң ун көннән дә иртәрәк үткәрелергә тиеш түгел.

3.6. Гражданнар җыены этаплап уздырылган очракта да, гражданнарның тавыш бирүе хокуклы, аннан соң барлык уздырылган этапларның йомгаклары буенча тавышларны санап, бердәм карар чыгарыла һәм бу җыенның бердәм узды дип саналуына китерә.

3.7.  Гражданнар җыенында ачык тавыш бирү каралган.

3.8. Гражданнар җыенында муниципаль берәмлек башлыгы, яки  гражданнар җыенында теркәлгән катнашучылар арасыннан ачык тавыш бирү юлы белән күпчелек тавыш алган башка кеше рәислек итә ала. Рәислек итүче кандидатураларын гражданнар җыенында катнашучылар тәкъдим итә ала.

3.9. Гражданнар җыены сәркатипне һәм хисап комиссиясен сайлый. Хисап палатасы әгъзалары саны өч кешедән артык булырга тиеш түгел.

Хисап комиссиясенә рәислек итүче керә алмый.

Хисап комиссиясе:

1) торак пунктта яшәүчеләр җыенына килүче гражданнарны теркәүнең дөреслеген, кирәк булганда, аларның гражданнар җыены эшендә катнашу хокукын тикшерә;
2) гражданнар Җыенының кворумын билгели (гражданнар җыены этапларын үткәрүдән тыш);
3) тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирә;
4) тавышларны саный һәм тавыш бирүгә йомгак ясый (гражданнар җыены этапларын үткәрүдән тыш);
5) тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи (гражданнар җыены йомгаклары буенча);
6) рәислек итүчегә тавыш бирү нәтиҗәләре белән материаллар (беркетмә, җыенда катнашучы гражданнар исемлеге) тапшыра.

3.10. Гражданнар Җыенының көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр рәислек итүче, муниципаль берәмлек башлыгы, гражданнар җыенында катнашу хокукына ия гражданнар тарафыннан кертелә ала. Көн тәртибенә чакырылыш инициаторлары тарафыннан кертелгән сораулар мәҗбүри рәвештә карала. Күрсәтелгән мәсьәләләр беренче чиратта хәл ителә. Халык җыенының көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләрне кертү турында карар, әгәр аның өчен җыенда катнашкан гражданнарның яртысыннан да ким булмаган өлеше тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

3.11. Гражданнар җыены вакытында, шулай ук муниципаль берәмлек башлыгы, яисә ачык тавыш бирү юлы белән сайланган башка зат, гражданнар җыенында теркәлгән катнашучылар санынннан гади күпчелек тавыш белән, рәислек итә ала. Рәислек итүче кандидатураларын җыенда катнашучылар тәкъдим итәргә хокуклы.

3.12. Гражданнарның этаплап җыенында тавыш бирү ачык, яисә ябык (яшерен) булырга мөмкин.

Тавыш бирү формасы турындагы карар гражданнар җыены этабында кабул ителә (вариант буларак: форма гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә белән билгеләнә).

3.13. Гражданнар җыенын уздыру этапларының һәркайсында, этаплап җыен уздырганда, хисап комиссиясе арасыннан гражданнарның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча Хисап комиссиясенең бер әгъзасы сайлана, алар кворумны һәм йомгаклау тавышларын санаганда комиссия составында эшләячәк.

3.14. Гражданнар җыены җыенда рәислек итүче тарафыннан ачыла. Җыенда рәислек итүче гражданнарның җыенын оештыра, тәртипне саклый, хисап комиссиясенең эшенә кураторлык итә, тикшерелә торган мәсьәләләр буенча чыгыш ясау өчен сүз бирә, тавыш бирүнең билгеләнгән тәртибен тәэмин итә.

3.15. Гражданнар җыенында сәркатип тарафыннан беркетмә алып барыла, анда гражданнар җыенын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны, торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны, көн тәртибе, чыгышларның кыскача эчтәлеге, карала торган мәсьәләләр буенча тавыш биргән гражданнар саны (7 нче кушымта) күрсәтелә.

3.16. Халык җыенын этаплап уздырганда гражданнар Җыенының һәр этабында беркетмәләр алып барыла (8,9 нчы кушымталар), алар соңыннан гражданнар Җыенының уздырылган этаплары йомгаклары буенча җыенның бер йомгаклау беркетмәсенә (10 нчы кушымта), шулай ук хисап комиссиясе беркетмәләренә (11,12 нче кушымталар) тутырыла, алар шулай ук Халык җыенының һәр этабында тавышларны санау нәтиҗәләре буенча Хисап комиссиясенең бер йомгаклау беркетмәсенә (13 нче номерлы беркетмә) тутырыла.

3.17. Гражданнар Җыенының йомгаклау беркетмәсендә гражданнар җыены этапларының датасы, урыны һәм вакыты, көн тәртибе, гражданнар җыены этапларында катнашкан гражданнарның гомуми саны турында белешмәләр, гражданнар җыены этаплары нәтиҗәләре буенча тавыш бирүнең йомгаклау нәтиҗәләре теркәлә. Йомгаклау беркетмәсе җирлек башлыгы кул куя торган гражданнар җыены карарын рәсмиләштерү өчен нигез булып тора.

3.18. Беркетмә җыенда рәислек итүче зат һәм җыен сәркатибе тарафыннан имзаланып, муниципаль берәмлек башлыгына тапшырыла. Җыенда катнашучылар исемлеге беркетмәгә теркәлә.

3.19. Гражданнар Җыенының уздырылган этаплары йомгаклары буенча Хисап комиссиясенең йомгаклау беркетмәсендә гражданнар җыены этапларын үткәрү датасы, урыны һәм вакыты, көн тәртибе, үткәрелгән этаплар саны, халык җыеннарының үткәрелгән этаплары буенча хисап комиссиясе беркетмәләре саны, җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче гражданнарның гомуми саны, җыен эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны, җыен эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны, алар өчен бирелгән тавышларның гомуми саны һәм “Риза”, “Каршы” тавышларының гомуми саны.

3.20. Йомгаклау беркетмәсенә хисап комиссиясе рәисе һәм хисап комиссиясе әгъзалары кул куя һәм муниципаль берәмлек башлыгына тапшырыла.

## 4. Халык җыены карарлары.

4.1. Гражданнар җыенында катнашучыларның сайлау хокукына ия булган яртысыннан күбрәге тавыш бирсә, җыен карары кабул ителгән дип санала.

4.2. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып тора, муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.

4.3. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары гражданнар җыенында җирлек Уставы билгеләгән, алар арасындагы вәкаләтләрне чикләү нигезендә кабул ителгән карарларны үтәүне тәэмин итәләр.

4.4. Җыенда кабул ителгән карар юкка чыгарылырга яки җыенда башка карар кабул итү юлы белән үзгәртелергә, яисә суд тәртибендә гамәлдән чыккан, дип танылырга мөмкин.

4.5. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарлар рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) һәм муниципаль хокукый актлар өчен таләпләр нигезендә рәсмиләштерелергә тиешләр..

4.6. Торак пункт кешеләренең турыдан-туры ихтыярын белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә муниципаль хокук актын кабул итү (бастыру) таләп ителсә, компетенциясенә күрсәтелгән актны кабул итү (бастыру) керә торган җирле үзидарә органы яки вазыйфаи зат гражданнар җыенында кабул ителгән карар үз көченә кергән көннән алып 15 көн эчендә тиешле муницаиаль хокук актын әзерләү һәм (яки) кабул итү срогын билгеләргә тиешләр. Күрсәтелгән срок өч айдан арта алмый.

## Гражданнар җыены карарларын үтәү

4.7. Җыенда кабул ителгән карарлар торак пункт территориясендә мәҗбүри төстә үтәлергә тиешләр һәм нинди дә булса дәүләт хакимияте органнарының, аларның вазыйфаи затларының яки җирле үзидарә органнарының раславына мохтаҗ түгелләр.

4.8. Җыенда кабул ителгән карарларны үтәмәү закон нигезендә җаваплылыкка тартуга сәбәп булып тора.

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге торак пунктларында
гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны үткәрү
тәртибе турында”гы Нигезләмәгә
**1 нче кушымта**

**ИМЗАЛАР КӘГАЗЕ**

Без, түбәндә кул куючылар, ____________________________________________________
(гражданнар җыенын үткәрү сроклары)
гражданнар җыенын үткәрү инициативасын хуплыйбыз.

Чистай муниципаль районының ________________ авыл җирлегендә
______________________________________________________________________________
_________________________________________________________________сорауны тәгъбир итү

| Тәр-типсаны | Фамилия, исем, атасының исеме | Туу көне | Яшәү урыны адресы | Паспорт яки аны алмаштыручы документ сериясе, номеры | Имза кую датасы | имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Имзалар кәгазен раслыйм________________________________________________________

(имза җыючы кешенең фамилиясе, исеме, атасының исеме,
______________________________________________________________________________
туу көне,паспорты яки аны алмаштыручы документының сериясе, номеры)

_____________________ (имза һәм дата)

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге торак пунктларында
гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны үткәрү
тәртибе турында”гы Нигезләмәгә
**2 нче кушымта**

**Чистай муниципаль районыны**
**____________ авыл җирлеге**
**Советы**

**КАРАРЫ**

**____________ 20___** **№ _____**

Чистай муниципаль районы_______________________ җирле үзидарә органнарына гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 6 октябрь, 2003 ел, 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 28 июль, 2004 ел, 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче маддәсе һәм Татарстан Республикасы ________________муниципаль районының ___________________ авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының __________ маддәсен гамәлгә ашыру максатында,

КАРАР ИТТЕ:

1. Чистай муниципаль районының __________ авыл җирлеге ________________________торак пунктында 20** елның____ сәг.___мин. үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына кертелә торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез 2019 елда гражданнарга _________________ авыл җирлеге территориясендә теркәлгән балигь булган һәр кешегә (үзара салымнан азат ителгән гражданнардан кала) ___________ сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы?

ӘЙЕ ЮК».

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көннән соң _ көн эчендә игълан итәргә.

3. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

___________________ ___________________

**(**Фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге торак пунктларында
гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны үткәрү
тәртибе турында”гы Нигезләмәгә
**3 нче кушымта**

**Чистай муниципаль районы _____________авыл җирлеге башлыгы**

**карары**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы _________ авыл җирлеге
башлыгы, _____ 20___ ел N
Чистай муниципаль районы Чистай муниципаль районы җирлегенең _ _ _ _ торак
пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын билгеләү һәм куллану мәсьәләсе
буенча гражданнар җыенын үткәрү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 6 октябрь, 2003 ел, 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 28 июль, 2004 ел, 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче маддәсе һәм Татарстан Республикасы _______________муниципаль районының __________________ авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының __________ маддәсен гамәлгә ашыру максатында,

**Карар бирә**

1. Чистай муниципаль районының __________ авыл җирлеге __________________торак пунктында 20** елның _______ үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына кертелә торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез 2019 елда гражданнарга _________ авыл җирлеге территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешегә (үзара салымнан азат ителгән гражданнардан кала) _______ сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы? ________________________________________________

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көннән соң _ көн эчендә игълан итәргә.
3. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык _____________ ФИО ________

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге торак пунктларында
гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны үткәрү
тәртибе турында”гы Нигезләмәгә
**4 нче кушымта**

________________________________________ ________________________________________
(муниципаль район исеме) (авыл җирлеге исеме)

__________________________________ сайлау хокукына ия кешеләр
(торак пункт исеме)

**ИСЕМЛЕГЕ**

“____” ____________ 20 ел

| Тәр-тип саны | Фамилия, исем, атасының исеме | Туу көне(18 яше тулган затлар өчен туган көне һәм ае) | Яшәү урыны адресы | Паспорт яки аны алмаштыручы документ сериясе, номеры | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

Гражданнар җыенында рәислек итүче ________________________ ________________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)

Гражданнар җыены сәркатибе __________________________ __________________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге торак пунктларында
гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны үткәрү
тәртибе турында”гы Нигезләмәгә
**5 нче кушымта**

Чистай муниципаль районы ____________________авыл җирлеге Советы
_______ 20**ел. ______ № ____

**Карары**

Чистай муниципаль районы җирлегенең _ _ _ _ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 6 октябрь, 2003 ел, 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 28 июль, 2004 ел, 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче маддәсе һәм Татарстан Республикасы _______________муниципаль районының __________________ авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының __________ маддәсен гамәлгә ашыру максатында,

Карар итә:

1. 20** _____ ___сәгать ___ минутка Чистай муниципаль районы __________авыл җирлегенең _____ _ _ торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 20** _____ ___сәгать ___ минутка Чистай муниципаль районы __________авыл җирлегенең _____ _ _ торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Гражданнар җыенын билгеләү турында муниципаль актта торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген (территориаль, вакытлыча яки башка билге буенча) сайлау тәртибе күрсәтелә.
4. Гражданнар җыенына кертелә торган түбәндәге мәсьәләне расларга:
“Сез 2019 елда гражданнарга _________ авыл җирлеге территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешегә (үзара салымнан азат ителгән гражданнардан кала) _______ сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы? ______________________________________________

« РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көннән соң _ _ көн эчендә игълан итәргә.
6. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

____________
____________ ФИО ________
Җирлек башлыгы

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге торак пунктларында
гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны үткәрү
тәртибе турында”гы Нигезләмәгә
**6 нче кушымта**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы ____________________авыл җирлеге башлыгының “Чистай муниципаль районы җирлегенең _ _ _ _ торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”гы

**карары**

_______ 20**ел. ______ № ____

Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 6 октябрь, 2003 ел, 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 28 июль, 2004 ел, 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче маддәсе һәм Татарстан Республикасы _______________муниципаль районының __________________ авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының __________ маддәсен гамәлгә ашыру максатында,

КАРАР БИРӘ:

1. 20** _____ ___сәгать ___ минутка Чистай муниципаль районы __________авыл җирлегенең _____ _ _ торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 20** _____ ___сәгать ___ минутка Чистай муниципаль районы __________авыл җирлегенең _____ _ _ торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне сайлау тәртибе (территориаль, вакытлыча яки башка билгеләр буенча) муниципаль берәмлек башлыгының гражданнар җыенын билгеләү турында Карарында күрсәтелә.
4. Гражданнар җыенына кертелә торган түбәндәге мәсьәләне расларга:
   “Сез 2019 елда гражданнарга _________ авыл җирлеге территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешегә (үзара салымнан азат ителгән гражданнардан кала) _______ сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы? ______________________________________________

   « РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көннән соң _ _ көн эчендә игълан итәргә.

6. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык ____________ ФИО ________

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге торак пунктларында
гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны үткәрү
тәртибе турында”гы Нигезләмәгә
**7 нче кушымта**

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ БЕРКЕТМӘСЕ
______________________________________________

«___» ____________ 20__ ел № _____

______________________
(Торак пункт исеме)

Катнаштылар ______________________________________________________ кеше
(торак паунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Гражданнар җыенында
рәислек итүче ______________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Гражданнар җыены сәркатибе______________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

**КӨН ТӘРТИБЕ:**

**1.**
**2.**

ҖЫЕНДА РӘИСЛЕК ИТҮЧЕ САЙЛАНА:

ФИО – вазыйфасы

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Риза» - ____ кеше
«Каршы» ____ кеше

ҖЫЕН СӘРКАТИБЕ САЙЛАНА:

Рәислек итүче: җыен секретарен сайларга кирәк. Нинди тәкъдимнәр булачак?

Җыен секретаре итеп сайлау тәкъдиме бар

ФИО – вазыйфасы

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Риза» - ____ кеше
«Каршы» ____ кеше

ҖЫЕННЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:
Рәислек итүче: гражданнар җыены кворумын билгеләү, тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү, тавышларны санау һәм тавыш бирүгә йомгак ясау, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү өчен хисап комиссиясен сайларга кирәк.

Хисап комиссиясе рәисе һәм хисап комиссиясе әгъзалары итеп сайларга диган тәкъдим бар:

ФИО – вазыйфасы
ФИО – вазыйфасы

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Риза» - ____ кеше
«Каршы» ____ кеше

КӨН ТӘРТИБЕ БУЕНЧА ЭШ:

**Беренче мәсьәлә буенча тыңладылар** ________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(чыгышның кыскача эчтәлеге яки чыгыш темасы теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ____________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(чыгышның кыскача эчтәлеге яки чыгыш темасы теркәлә)

һ.б.лар (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

**КАРАР ИТТЕЛӘР:** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: “Әйе” _________________ кеше
“Юк” _________________ кеше
“Тавыш бирми калды” ____кеше

Карар ___________________________________________________________________________
кабул ителде (кабул ителмәде)

**Икенче мәсьәлә буенча тыңладылар** ________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(чыгышның кыскача эчтәлеге яки чыгыш темасы теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ____________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(чыгышның кыскача эчтәлеге яки чыгыш темасы теркәлә)

һ.б.лар (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

**КАРАР ИТТЕЛӘР:** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: “Әйе” _________________ кеше
“Юк” _________________ кеше
“Тавыш бирми калды” ____кеше

Карар ___________________________________________________________________________
кабул ителде (кабул ителмәде)

Гражданнар җыенында рәислек итүче ________________________ ________________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)

Гражданнар җыены сәркатибе ______________________________ ________________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге торак пунктларында
гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны үткәрү
тәртибе турында”гы Нигезләмәгә
**8 нче кушымта**

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЭТАБЫ БЕРКЕТМӘСЕ**

«___» ____________ 20__ ел №_____

______________________
(Торак пункт исеме)

Катнаштылар _______________________________________________ кеше
(торак паунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Гражданнар җыенында
рәислек итүче _____________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Гражданнар җыены сәркатибе_________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

**КӨН ТӘРТИБЕ:**

1.

2.

ҖЫЕНДА РӘИСЛЕК ИТҮЧЕ САЙЛАНА:

ФИО – вазыйфасы

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Риза» - ____ кеше
«Каршы» ____ кеше

ҖЫЕН СӘРКАТИБЕ САЙЛАНА:

Рәислек итүче: җыен секретарен сайларга кирәк. Нинди тәкъдимнәр булачак?

Җыен секретаре итеп сайлау тәкъдиме бар

ФИО – вазыйфасы

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Риза» - ____ кеше
«Каршы» ____ кеше

ҖЫЕННЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:
Рәислек итүче: гражданнар җыены кворумын билгеләү, тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү, тавышларны санау һәм тавыш бирүгә йомгак ясау, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү өчен хисап комиссиясен сайларга кирәк.

Хисап комиссиясе рәисе һәм хисап комиссиясе әгъзалары итеп сайларга дигән тәкъдим бар:
ФИО – вазыйфасы
ФИО – вазыйфасы

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Риза» - ____ кеше
«Каршы» ____ кеше

КӨН ТӘРТИБЕ БУЕНЧА ЭШ:

**Беренче мәсьәлә буенча тыңладылар** ________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(чыгышның кыскача эчтәлеге яки чыгыш темасы теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ______________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(чыгышның кыскача эчтәлеге яки чыгыш темасы теркәлә)

һ.б.лар (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

**КАРАР ИТТЕЛӘР:** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: “Әйе” ________________ кеше
“Юк” ________________ кеше
“Тавыш бирми калды” ____кеше

Карар ______________________________________________________________________________

кабул ителде (кабул ителмәде)

**Икенче мәсьәлә буенча тыңладылар** ________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(чыгышның кыскача эчтәлеге яки чыгыш темасы теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ______________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(чыгышның кыскача эчтәлеге яки чыгыш темасы теркәлә)

һ.б.лар (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

**КАРАР ИТТЕЛӘР:** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: “Әйе” ________________ кеше
“Юк” ________________ кеше
“Тавыш бирми калды” ____кеше

Карар ______________________________________________________________________________

кабул ителде (кабул ителмәде)

Гражданнар җыенында рәислек итүче _______________________ _______________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)

Гражданнар җыены сәркатибе _____________________________ _______________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге торак пунктларында
гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны үткәрү
тәртибе турында”гы Нигезләмәгә
**9 нче кушымта**

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ ИКЕНЧЕ ЭТАБЫ БЕРКЕТМӘСЕ**

«___» ____________ 20__ ел № _____

______________________
(Торак пункт исеме)

Катнаштылар _______________________________________________________________ кеше
(торак паунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны, катнашучылар саны)

Гражданнар җыенында
рәислек итүче _________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Гражданнар җыены сәркатибе______________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

**КӨН ТӘРТИБЕ:**

1.

2.

ҖЫЕНДА РӘИСЛЕК ИТҮЧЕ САЙЛАНА:

ФИО – вазыйфасы

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Риза» - ____ кеше
«Каршы» ____ кеше

ҖЫЕН СӘРКАТИБЕ САЙЛАНА:

Рәислек итүче: җыен секретарен сайларга кирәк. Нинди тәкъдимнәр булачак?

Җыен секретаре итеп сайлау тәкъдиме бар

ФИО – вазыйфасы

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Риза» - ____ кеше
«Каршы» ____ кеше

ҖЫЕННЫҢ ХИСАП КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:

Рәислек итүче: гражданнар җыены кворумын билгеләү, тавыш бирү мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү, тавышларны санау һәм тавыш бирүгә йомгак ясау, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү өчен хисап комиссиясен сайларга кирәк.

Хисап комиссиясе рәисе һәм хисап комиссиясе әгъзалары итеп сайларга дигән тәкъдим бар:
ФИО – вазыйфасы
ФИО – вазыйфасы

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Риза» - ____ кеше
«Каршы» ____ кеше

КӨН ТӘРТИБЕ БУЕНЧА ЭШ:

**Беренче мәсьәлә буенча тыңладылар** ______________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(чыгышның кыскача эчтәлеге яки чыгыш темасы теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(чыгышның кыскача эчтәлеге яки чыгыш темасы теркәлә)

һ.б.лар (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

**КАРАР ИТТЕЛӘР:** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: “Әйе” _________________ кеше
“Юк” _________________ кеше
“Тавыш бирми калды” ____кеше

Карар ______________________________________________________________________
кабул ителде (кабул ителмәде)

**Икенче мәсьәлә буенча тыңладылар** ______________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(чыгышның кыскача эчтәлеге яки чыгыш темасы теркәлә)

**Чыгыш ясадылар:** 1. ________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

(чыгышның кыскача эчтәлеге яки чыгыш темасы теркәлә)

һ.б.лар (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

**КАРАР ИТТЕЛӘР:** (карарның эчтәлеге)

Тавыш бирү нәтиҗәләре: “Әйе” _________________ кеше
“Юк” _________________ кеше
“Тавыш бирми калды” ____кеше

Карар ______________________________________________________________________
кабул ителде (кабул ителмәде)

Гражданнар җыенында рәислек итүче _______________________ _______________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)

Гражданнар җыены сәркатибе _____________________________ _______________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге торак пунктларында
гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны үткәрү
тәртибе турында”гы Нигезләмәгә
**10 нче кушымта**

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ УЗДЫРЫЛГАН ЭТАПЛАРЫ НӘТИҖӘЛӘРЕ БУЕНЧА ҖЫЕННЫҢ ЙОМГАКЛАУ БЕРКЕТМӘСЕ

_______________________________________
(Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы торак пункты исеме)

«______» _________ 20__ ел 00 сәг 00 мин № ____

Гражданнарның беренче этабы _______20 ___ел, ______нче номерлы (Рәислек итүче ФИО), ______20__ел, ____нче номерлы Гражданнарның икенче этабы беркетмәсенә (Рәислек итүче ФИО) нигезләнеп билгеләнгән сорау буенча этаплап гражданнар җыеннары үткәрелде.

1. Җыенның үткәрелгән этапларының тавыш бирү формасы (ачык, яки ябык (яшерен) күрсәтелеп) саны_______
2. Гражданнар җыеннарының этаплап уздырыла торган беркетмәләре саны ______
3. Җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм аларның эшендә катнашырга хокукы булган гражданнарның гомуми саны __________;
4. Сайлау хокукына ия ______һәм гражданнар җыены этапларында катнашкан гражданнарның гомуми саны ___________

Карар иттеләр: (карарның эчтәлеге)

- Гражданнар җыены этапларында кертелгән мәсьәлә өчен бирелгән тавышларның гомуми саны _________ “РИЗА” _____, “КАРШЫ”_____;
- Кертелгән мәсьәләгә “Каршы” бирелгән тавышларның гомуми саны_______

Карар: кабул ителде (кабул ителмәгән очракта, сәбәпләрен күрсәтергә)

Гражданнар җыенында рәислек итүче _______________________ _______________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)
Гражданнар җыены сәркатибе _____________________________ _______________________
(имза) (имзаны расшифровкалау)

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге торак пунктларында
гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны үткәрү
тәртибе турында”гы Нигезләмәгә
11 **нче кушымта**

ХАЛЫК ҖЫЕНЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЭТАБЫНЫҢ
ХИСАП КОМИССИЯСЕ БЕРКЕТМӘСЕ

**Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай авыл җирлеге ___________составына керүче ______________торак пунктында тавыш бирү нәтиҗәләре турында**

«_____» _______ 2019 ел № 1
авыл исеме

Катнашалар: хисап комиссиясе әгъзалары:
1. ФИО;
2. ФИО;
һ.б.
Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия булган_________ гражданнар катнаша .

Гражданнар Җыенының беренче этабы көн тәртибе буенча тавыш бирү нәтиҗәләре:

«_____________________________________________________________________»

“РИЗА”___________тавыш

“КАРШЫ”_________тавыш

Хисап комиссиясе рәисе ФИО

Хисап комиссиясе әгъзалары: ФИО

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге торак пунктларында
гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны үткәрү
тәртибе турында”гы Нигезләмәгә
**12 нче кушымта**

ХАЛЫК ҖЫЕНЫНЫҢ ИКЕНЧЕ ЭТАБЫНЫҢ
ХИСАП КОМИССИЯСЕ БЕРКЕТМӘСЕ

**Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай авыл җирлеге ___________составына керүче ______________торак пунктында тавыш бирү нәтиҗәләре турында**

«_____» _______ 2019 ел № 1

авыл исеме

Катнашалар: хисап комиссиясе әгъзалары:

1. ФИО;
2. ФИО;

һ.б.

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия булган_________ гражданнар катнаша .

Гражданнар Җыенының беренче этабы көн тәртибе буенча тавыш бирү нәтиҗәләре:

«_______________________________________________________________________»

“РИЗА”___________тавыш

“КАРШЫ”_________тавыш

Хисап комиссиясе рәисе ФИО

Хисап комиссиясе әгъзалары: ФИО

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге торак пунктларында
гражданнар җыенына әзерләнү һәм аны үткәрү
тәртибе турында”гы Нигезләмәгә
**13 нче кушымта**

Халык җыенының беренче, икенче һәм (һ. б.) этапларында
тавыш бирү нәтиҗәләре буенча

ХИСАП КОМИССИЯСЕ БЕРКЕТМӘСЕ

___________________________________
(Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы_________авыл җирлеге _______ торак пункты исеме)

«___» ____________ 20__ ел ___________________________________
(торак пунктның исеме)
Гражданнар Җыенының беренче, икенче (һ. б.) этаплары нәтиҗәләре
________________________________________________________________________
(территориянең исеме
________________________________________________________________________
муниципаль берәмлегенең яисә аның өлешенең)
Гражданнар Җыенының этапларын үткәрү датасы һәм вакыты: _______________
_____________ 20__ ел
Гражданнар җыеннарында тавыш биргәндә тавышларны санау нәтиҗәсендә:
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

Хисап комиссиясе билгеләде:

1. Халык җыенының үткәрелгән этаплары саны ____________________________;
2. Гражданнар җыены этапларының үткәрелгән хисап комиссиясе беркетмәләренең тәкъдим ителгән саны ___________________;
3. Җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм җыен эшендә катнашырга хокуклы гражданнарның гомуми саны __________;
4. Җыен эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны ___________________;
5. Гражданнар җыенына кертелгән мәсьәлә өчен “РИЗА” дип бирелгән тавышларның гомуми саны _______;
6. Гражданнар җыенына кертелгән мәсьәлә өчен “КАРШЫ” дип бирелгән тавышларның гомуми саны _______;

КАРАР ИТТЕЛӘР:

Мәсьәлә буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен расларга _________________, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә, мәсьәлә буенча җыен карары____________________кабул ителгән дип санарга.

Хисап комиссиясе рәисе ______________________ _______________
(фамилиясе, инициаллары) имза
Хисап комиссиясе әгъзалары 1. __________________________ _______________
(фамилиясе, инициаллары) имза
Беркетмә төзелде «___» _____________ 20___ел.